Әлмәт шәһәре 37-нче «Әкият» компенсация төрендәге балалар бакчасы мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе



# Юл фәне иленә сәяхәт

**Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү буенча методик куллама**

Әлмәт
2012

Әлмәт шәһәре 37нче “Әкият” компенсация төрендәге балалар бакчасы мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениясенең тәрбиячесе

**Вәлиева Миләүшә Мәзхәт кызының**

“Юл фәненә сәяхәт” мәктәпкәчә яшьтәге балаларны юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү буенча методик кулланмасына

**б ә я л ә м ә**

Соңгы елларда дәүләтебездә транспорт, бигрәк тә җиңел машиналарның саны арту нәтиҗәсендә юл-транспорт һәлакәтләре ешайды, аларда имгәнүчеләр, һәлак булучылар арасында балалар саны да күбәйде. Болар – юл йөрү кагыйдәләре, юлдагы иминлек мәсьәләсе өстендә эш җитмәвенең күрсәткече. Бу яктан караганда тәрбияче М.М.Вәлиеваның “Юл фәненә сәяхәт” дигән методик кулланмасы аеруча актуаль хезмәт.

Тәрбияче М.Вәлиева эшләгән методик кулланма сөйләмдә кимчелекләре булган мәктәпкәчә яшьтәге балаларга исәпләнгән булса да, ул гадәти балалар белән эшләүдә дә уңышлы файдаланыла ала. Әлеге мөмкинлек кулланмада мәктәпкәчә яшьтәге балаларны ирекле иҗади шәхес буларак тәрбияләү, аларны юл кагыйдәләренә өйрәтү, балаларның иминлекләрен, сәламәтлекләрен саклау, танып белү, иҗади күзаллау, фикерләү сәләтен, аралашу осталыкларын үстерү буенча проект үрнәкләре һәм төрле типтагы эшләр (әвәләү, кисеп ябыштыру, рәсем ясау һ.б.) бирелү белән аңлатыла.

Кулланмада даими рәвештә ата-аналар һәм балалар катнашындагы эшләр (стена газетасы чыгару, башваткычлар төзү, гаилә ярышлары үткәрү һ.б.) тәкъдим ителү авторның һәртөрле тәрбиянең ата-анадан башлануын һәм тәрбияче тарафыннан үстерелүен, камилләштерелүен аңлап эш итүен дәлилли.

“Юл фәне иленә сәяхәт” методик кулланмасы эзлекле язылган аңлатма язуыннан, проектларны, дәрес-уеннарны, ял сәгатьләрен, бәйрәм сценарийларын туплаган төп өлештән һәм кулланылган әдәбият исемлегеннән тора. Һәр проект тиешле фәнни-методик аңлатмалар белән, федераль дәүләт таләпләренә, мәктәпкәчә яшьтәге балаларны юлларда хәвефсез тотарга өйрәтүнең төбәк системасына нигезләнеп эшкәртелеп бирелгән, сайланган эш төрләре тәрбияче куйган максатларга ирешүгә хезмәт итә.

Хезмәтнең тагын бер уңышлы, уңай ягы – татар төркемнәрендә эшләүне күздә тотуы. Методик кулланмадагы эш төрләре мәктәпкәчә яшьт әге балаларның татар телендә сөйләшү-аралашу, фикер йөртү сәләтләрен үстерүдә дә әһәмиятле һәм уңышлы чара булып тора.

М.Вәлиеваның “Юл фәне иленә сәяхәт” дигән мәктәпкәчә яшьтәге балаларны юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү буенча методик кулланмасы әлеге төр хезмәтләргә куела торган заманча таләпләргә туры килә.

Филологгия фәннәре кандидаты,
ӘДМХИ доценты Р.А Ласкова

ОТДЕЛ КАДРОВ
ИНН 1644011469
КПП 164401001

Подпись Ласковой Р.А. заверяю.

13.03.2012 г.